ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ОКТЯБРЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ОКТЯБРЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

01.12.2020 | 61

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003нче елның 6нчы октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирле референдум турында» 2004нче елның 24нче мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Югары Ослан муниципаль районының Октябрьский авыл җирлеге Уставы нигезендә, 2020нче елның 12нче ноябрендәге 1нче номерлы; 2020нче елның 14нче ноябрендәге 2нче һәм 3нче номерлы, 2020нче елның 15нче ноябреннән 4нче номерлы гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны тормышка ашыру максатларында, Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитеты

Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен үзем контрольдә тотам.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге башлыгы Ш. Р. Азизов

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Октябрьский авыл җирлеге Башкарма
комитетының 2020нче елның 1нче
декабреннән 61-ТРЗ карарына
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

1. Әлеге Тәртип Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлегендә үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели

2. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге территориясендә теркәлгән 18 яше тулган гражданнар җыеннарында катнашуларына һәм тавыш бирүдә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, үзара салым акчаларын түләү 2021нче елның 1нче гыйнварыннан 2021нче елның 31нче мартына кадәр башкарыла.

3. Түбәндәге категория гражданнар үзара салым акчаларын түләүдән азат ителә:
а) Бөек Ватан сугышы инвалидлары;
б) Бөек Ватан сугышында катнашучылар.
4. Аерым категория гражданнар өчен:
а) 1нче төркем инвалидлар,
б) күп балалы гаиләләр,
в) көндезге уку йортлары студентлары,
г) Бөек Ватан сугышы ветераннары
түләү күләме гражданнар җыены турындагы карарда билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.
4. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү (хәбәрнамә) бланкы имза яки почта элемтәсе аша юллау юлы белән гражданнарга җиткерелә. Хәбәрнамәдә (хәбәр итү) гражданнарга үзара салым акчаларын күчерүнең түләү реквизитлары, тулы яки киметелгән күләмдә бер тапкыр түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

5. Югары Ослан муниципаль районы Октябрьский авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси счетына гражданнардан җыелган үзара салым акчалары керә

6. Гражданнар тарафыннан түләүләр физик затлар кушуы буенча исәп-хисапларны гамәлгә ашыру хокукына ия оешмалар аша акчалар күчерү юлы белән почтадан акча күчерү юлы белән (исәп-хисап оешмалары) яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы https://uslugi.tatarstan.ru/ ссылкасы аша башкарыла.

7. Керем касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар түләү фактын раслый.

8. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.